ГЛАВА ОМАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Омары,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422183

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОМАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Омар авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422183

тел.(факс): (85563) 2-82-47; e-mail: Omar.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление — Карар

“21” октября 2020 г. — № 2

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегенең Омар торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Омар авыл җирлеге муниципаль берәмлеге” Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Омар авылы , Мәктәп урамы , 18 нче йорт адресы буенча урнашкан Омар авылы мәдәният йорты бинасында 2020 елның 20 ноябре сәгать 13.00дә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегенең Омар торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегенең Омар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында катнашканнарның тол хатыннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-Омар торак пунктында Приречная урамы, Югары урамы (сатып алу, ташу, вак таш җәю, кырдырып тигезләү, килешү буенча эш өчен түләү;);

- Омар торак пунктында юлларны кардан чистарту;

- Омар торак пунктында урамнарны яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, махсус җиһазларны сатып алу һәм алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү)

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге башкарма комитетына Омар торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Омар авыл җирлеге башлыгы: Л.Н.Хәбибуллин